*Мәктәп туры*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
ТАТАР ӘДӘБИЯТЫННАН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕНЕҢ
**ҖАВАПЛАРЫ**

(2024-2025 нче уку елы)
**8 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 120 минут**
**Максималь балл – 45**

**1. Риваятьләр турында исеңә төшер. Аларның үзенчәлекләрен барлап яз, мисаллар китер. (7 балл)**

**Җавап:** Риваять – татар халык авыз иҗатының бер төре. Риваять – тарихи вакыйга һәм шәхесләр турында буыннан-буынга тапшырылып килгән хикәят, истәлек. Риваятьләр әлеге тарихи вакыйгаларның шаһиты булган кешеләр авызыннан сөйләнә. Аларда халыкның тарихи үткәне, иҗтимагый тормышындагы мөһим вакыйгалар, күренекле шәхесләрнең эшчәнлеге турында сүз бара. Риваятьләрне ике төркемгә тарихи һәм топонимик төрләргә бүлеп йөртәләр. Тарихи риваятьләр халкыбызның тарихын яктырта («Хан кызы Алтынчәч», «Сихерче кыз», «Болгар каласының корылуы турында», «Яңа Казан каласының корылуы» һ.б.). Топонимик риваятьләр авыл, шәһәр исемнәренең, төрле географик атамаларның барлыкка килүен аңлата.

**2. Рәсемне кара. Ул кайсы әсәргә карата ясалган? Әсәрнең исемен, авторын яз, әсәр геройларын ата. (6 балл)**



**Җавап:** Г. Ибраһимов. «Табигать балалары»

Әсәр геройлары: хикәяләүче герой, Әсма, Бәдри карчык, Фәрхи җиңги, Шаһи бабай, Кәрим, Гыйлаҗи, малайлар.

**3. Әсәрләрнең авторын, жанрын яз. (6 балл)**

а) «Алсу» ____________________ __________________

ә) «Монда тудык, монда үстек» ___________________ _________________

б) «Матурлык» _____________________ __________________

**Җавап:**

а) «Алсу» Һади Такташ поэма

ә) «Монда тудык, монда үстек» Туфан Миңнуллин драма

б) «Матурлык» Әмирхан Еники хикәя

**4. Шигырьнең исемен, авторын яз. Шигырьне тулысы белән искә төшереп, анда бирелгән хис-кичерешләрне билгелә. (10 балл)**

Кошлар моңы уятадыр сине,
Челтәр пәрдәләрне күтәреп,
Язгы таңны күзлисеңдер ялгыз

Чәчәк аткан гөлләр үтәли.

Ә биредә, без фашистлар белән
Бугазлашкан урман, кырларда,
Күңел өчен бер генә кош та юк
Язны хәтерләтеп җырларга.

Дулкынланып, шаулап торган урман
Сынып беткән, изрәп тапталган,
Чәчәк үсә торган киң болыннар
Кеше каны белән тапланган.

**Җавап:** Фатих Кәрим. «Бездә яздыр».

Хис-кичерешләр: сагышлану, нәфрәтләнү, кайгыру.

**5. Портретка игътибар ит. Биредә кем сурәтләнгән? Бу шагыйрь турында өч фактны искә төшереп яз. (6 балл)**



1) ____________________________
2) ____________________________
3) ____________________________

**Җавап:**

1) Муса Җәлил 1906 елның 15 нче февралендә Оренбург өлкәсе Мостафа авылында туа.

2) Муса Җәлил – Советлар Союзы герое, тоткынлыкта фашистларга каршы яшерен эш алып барганы өчен җәзалап үтерелә.

3) Аның «Моабит дәфтәре» исемле шигырьләр циклы бар һ.б.

**6. Илнең күрке – тынычлык, диләр. Ничек уйлыйсың, бу дөресме? Бу турыда фикерләреңне яз, әдәбияттан мисаллар китерергә дә онытма. (10 балл)**